# Мәктәбем минем

**Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми белем мәктәбе укучыларының нәфис басмасы**



**27 май, 2013ел**
**№4**


## Әлеге санда:




**Мәктәп дәрьясында… Тәбрик итәбез! (2 нче бит)**





**Тарих сәхифәләре (2 нче бит )**





**Сәлам, Универсиада – 2013! (3 нче бит)**





**Илһам канатында (4 нче бит )**


## Соңгы звонок, соңгы дәрес, ник бераз соңламадын...

Бөтен илдәге кебек, безнең 78 нче мәктәптә дә 25 нче май көнне “Соңгы кыңгырау” чыңлады. Быел мәктәп тәмамлаучылар – 85 укучы (9 нчы сыйныф), 71 укучы (11 нче сыйныф). Быелгы чыгарылышны, һәрвакыттагыча, бөтен мәктәп, укучыларның әти-әниләре, кунаклар билгеләп үттеләр.

1 нче сентябрьдә игътибар үзәгендә беренче сыйныфлар булса, май аеның шушындый матур көнендә карашлар унберенче сыйныф укучыларына төбәлде.

Мәктәпне тәмамлаучыларны котларга керешкәнче, тугызынчы сыйныфларга төп мәктәп курсы өчен йомгаклау аттестациясен узарга, ә унберенче сыйныфларга бердәм дәүләт имтиханнарын тапшырырга рөхсәт ителү турындагы боерыклар укылды. Балаларны иң беренче булып үзенчәлекле һәм гомергә



истә кала торган көн белән мәктәп директоры Әлфия Гусмановна Урманчеева котлады, аларга, барыннан да бигрәк, имтиханнарда уңышлар теләде. “2013 ел укучысы” исемен яулаган 9 Б сыйныфы укучысы Шубина Марияне котлап, директор үз фондыннан премия бирде.

Мәктәп тәмамлаучылар үзләре дә укытучыларына шатлыклы һәм моңсу хисләр белән сугарылган шигырь юллары аша рәхмәт белдерделәр. Күңелле музыка яңгырады һәм алар башка өлкән сыйныф укучылары белән бергә вальс та биеделәр. Бу бәйрәмнең иң матур, иң тәэсирле мизгелләреннән берсе булды.

Уңышлар, сезгә, яшьләр!

**Мөхәррирләр**


## Мәктәп хәбәрләре:

1. «Ватанга хезмәт итәм» конференциясендә: 1 нче урынны – Абдуллина Зәринә; 2 нче урынны – Агитбригада «Патриот», Гордеева Камилә, Клюева Арина; 3 нче урынны – 4Г сыйныфы коллективы һәм 4 В сыйныфы укучысы Идрисов Радик яулады.
2. «Балкыш» татар театр студиясе Г.Тукайның 127 еллыгына багышланган «Шигъри сүз” район конкурсында дипломга лаек булды. Яшь артистлар: Мотыйгуллина Г.(5 М), Гиматдинов И.(5 М), Гильмутдинов А. (5 М), Газизянов Д.(5 М),(җитәкчесе: Л.М. Фатхуллова). Хәбирова Л.,11 А (җитәкчесе: М.З. Хәмидуллина ), Мотыгуллина Г., 5 М (җитәкчесе: Ә.Х. Миннегалиева), Идрисов Р.,4 В (җитәкчесе: Г.Г.Нуриева).
3. Габдулла Тукай мирасын өйрәнүгә багышланган “Без – Тукайлы халык” III республикакүләм Габдулла Тукай укуларында Рәхиева З. II урынны алды. (Җитәкчеләре: М.З. Хәмидуллина, Ә.Н. Рәхиева).
4. М.Т. Инсафетдинова “Интернет татарча сөйләшә” номинациясендә актив катнашып “Рәхмәт хаты” һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнде.
5. «2013 ел укучысы» исемен 9 Б сыйныфы укучысы Шубина Мария алды. Мәктәп директоры аңы җиңүе белән котлап, үз фондыннан премия бирде.
6. 72 нче беренча май җиңел атлетика республика конкурсында безнең мәктәп командасы I нче урынны яулады. Яшь спортсменнар: Артюхин А., Захаров В., Каримов Д., Петров Д., Прокофьев Ф., Сиразиев А. (җитәкче: Т.Г.Ильясов).

## Тарих сәхифәләрендә

### Татар халкының бөек шагыйре—Габдулла Тукайга 127 ел!

Татар әдәбияты үсешенә Габдулла Тукай кебек зур өлеш керткән башка каләм иясен табу кыен. Алай гына да түгел, ул тугандаш төрки һәм Идел-Урал буйларындагы мари, удмурт, чуваш сүз сәнгатьләренең чәчәк атуына да зур йогынты ясады. Дөресен әйткәндә, Габдулла Тукай элеккеге зур илдәге барлык халыклар өчен дә ят булмады, киресенчә, аның әсәрләре тәрҗемә ителмәгән, чын мәгънәсендә югары сәнгатьчә шигырьләре яңгырамаган телләрне табу кыендыр. Г. Тукай татар халкын илебездә һәм дөнья күләмендә танытуда илче хезмәтен үтәде дисәк тә, хилафлык булмас. Тукай дигәндә — татар' халкы күздә тотылса, татарлар дип әйтүгә — Г. Тукай дигән шигъри исем аңга килә.



Чөнки, зур исәптән караганда, Г. Тукай шагыйрь генә түгел, бәлки халкыбызның теле дә, моңы да, рухы да, язмышы да. Ул чын мәгънәсендә халыкның үз улы, шуңа күрә аның хасиятләрен, мәнфәгатьләрен тирән белүче һәм шул чор сәнгатьлелекнең иң югары күләмендә сурәтләп бирүче иде. Инде бөек шагыйребезне бездән аерган XX йөз дә «узган гасыр» булып тарихка кереп калды Әмма Габдулла Тукайның шәхесе һәм ул тудырган үлемсез әсәрләр һәрвакыт халык күңелендә, «безнең гасыр»да калалар. Бу — шагыйрьнең рухи үлемсезлеге дигән сүз.

Сөекле шагыйребезнең исемен телгә алуга, үзеннән-үзе аның «Исемдә калганнар» дигән язмаларында бәян ителгәннәр хәтергә килә. Шуларга менә бу мәгълүм юллар өстәлә: «Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?! Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.»

Г. Тукайга иҗат итү өчен язмыш тарафыннан бары сигез ел гына вакыт бирелгән булып чыкты. 1905 елда аеруча ялкынланып яза башлаган каләме 1913 елның апрелендә туктап калды. Ләкин зур талантларның гомер озынлыгы еш кына аның ничә ел каләм тибрәтүе белән түгел, бәлки үзеннән нинди әдәби мирас калдыруы белән билгеләнә.

**Интернет ресурстан**

## Мәктәп дәрьясында… Теләкләр!

**78 нче мәктәп укытучылары һәм укучылары туган көннәрен билгеләп үтүче укытучыларны котлый:**

**Хәмидуллина Мәрзия Зәкиевна**
**Абдуллина Лилия Ренатовна**
**Фәтхуллина Ләйсән Мәхмутовна**
**Абдуллина Светлана Гаязовна**
**Вирцева Ирина Михайловна**
**Волкова Светлана Михайловна**
**Ильясов Таһир Гайсович**
**Крашенинникова Нәсимә Идиятуллов-на**
**Пирогова Елена Олеговна**
**Родионова Светлана Ивановна**
**Смолярова Ольга Владимировна**
**Халитова Лариса Александровна**
**Харитонова Светлана Александра**
**Шиханова Алла Владимировна**



*Сезгә насыйп булган бәхет, шатлык,*
*Якты көннәр мәңге үтмәсен.*
*Сәламәтлек – ярты бәхет, диләр,*
*Шунысы бигрәк читләп үтмәсен.*
*Бәхет чишмәләрегез мул аксын,*
*Зур шатлыклар белән таң атсын!*

## Ишеттегезме әле?

2013 елгы Универсиадага кадәр Татарстанда спорт радиосы эшли башлаячак. Проектны Казандагы «Европа плюс» генераль директоры, «ММ-Пресс» җитәкчесе М.Ибләминов әзерли. Аның сүзләренә караганда, радиостанция өлешчә бәйсез булачак һәм тапшыруларны 93,5 МГц ешлыгында алып барачак.

***

Универсиадага эләгү кыйммәткә төшмәячәк. Әйтик, шахмат һәм самбо буенча ярышларга билетлар 30 сумнан башлана. Ә Җәйге уеннарның ачылу һәм ябылу тантаналарын күрү өчен, урынына ка-рап, 750 — 6000 сум түләргә туры киләчәк. Универсиадага дип барлыгы 207 млн сумлык 1 млн 260 мең данә билет сатарга җыеналар.

*        *        *

Казанга һәм 2013 елгы җәйге Универсиадага багышланган иң яхшы җырга бәйге игълан ителгән иде. Иң яхшы 13 җырны композитор Игорь Крутой рәислегендәге жюри сайлап алачак. Җиңүчеләр «Казан турында иң яхшы җыр», «Универсиада турында иң яхшы җыр», «Спорт, син — тынычлык илчесе» дигән номинацияләрдә билгеләнәчәк. Ә Гран-при иясенең җырына видеоклип төшереләчәк һәм аны Универсиада көннәрендә күрсәтәчәкләр.

***

Универсиаданы Казан яңа яр буе белән каршыларга җыена. Ул шәһәр үзәгендә — Ленин дамбасы белән Миллениум күпере арасында урнашачак.

***

2013 елгы Казан Универсиадасы Бөтендөнья студентлар уеннары тарихында катнашучыларның ярышлар үткәрүче илгә керү өчен виза алырга кирәк булмаган беренче Универсиада булачак. Чит ил хөкемдарлары һәм арбитрлары да Россиягә визасыз керә һәм чыга алачак, бары үзләре белән шәхесләрен һәм Универсиадага аккредитацияне раслаучы документлары гына булу мәҗбүри.

**Интернет ресурстан**

## Универсиадага рәхмәт!

Көрәш буенча Россия студентлары арасында Казанда узган ярышлар милли төребез тарихында яңа бер сәхифә ачылуын күрсәтте. Хәзер инде халыкара танылу аласы гына калды.

Казанда Бөтендөнья студентлары Универсиадасы тарихында беренче тапкыр татарча көрәш буенча сайлап алу турниры үтте. Аңлашыла ки, уеннарда милли төребез тәүге тапкыр үз урынын алачак. Әлеге вәзгыятьне безнекеләргә Универсиадага аерым спорт төрләрен хуҗа буларак кертә алу мөмкинлеге бирде. Шул рәвешле, татарның милли спорт көрәше белән бөтен дөнья халкы, спорт җәмәгатьчелеге таныша алачак.

Дөрес, ошбу спорт төре “Көрәш” дигән исем алачак. Хәбәр иткәнебезчә, көрәшебез, ниһаять, Россиянең Спорт министрлыгы тарафыннан илкүләмендәге спорт төре буларак танылды. Анда исә “татарча” дигән сүз булырга тиеш түгел икән, янәсе, ул очракта көрәш белән бары татарлар гына көрәшергә тиеш булачак. Хәер, анысы инде артык мөһим дә түгелдер. Ниһаять, безнең көрәшчеләр дә рәсми рәвештә “Россиянең спорт остасы”, тренерлар исә төрле категорияләр, “Россиянең атказанган тренеры” исемнәрен алу мөмкинлегенә ия булачак.

Россиянең татарча көрәш федерациясе президенты Җәүдәт Миннәхмәтов белдергәнчә, әлеге канун көрәш ярышларын оештырганда да зур роль уйный алачак. Чыннан да, моңа кадәр көрәшебез Татарстанга гына кирәк дигән тәэсир кала иде, төрле ярышлар уздырганда да төп авырлык республика, федерация, Җәүдәт Мидхәт улы үзе тапкан иганәчеләр җилкәсенә төшә иде. “Хәзер исә мин әнә шул документка нигезләнеп, теләсә кайсы төбәк вәкилләренә шатлыратып та көрәшебезне үстерү буенча тәкъдимнәрен җиткерә алачакмын”, - ди федерация президенты.

Россиянең спорт министры урынбасары Наталья Паршикова милли төребезнең, ниһаять, Мәскәү тарафыннан танылуының аерым сәбәпләрен атады. “Универсиада программасына кертелгәч кенә без көрәшнең аерым бер төбәктә генә яши һәм үсә алуына игътибар иттек. Шунысын да беләм, бөтенроссия реестрына керү турында татарстанлылар инде күптән эш алып баралар иде, - диде ул. – Ә бит уйлап карасаң, бездә башка илләрнең, халыкларның милли төрләре үсештә, әйтик, ушбу, айкидо... Бу яктан караганда, без үз милли спорт төрләребезнең, шушы төрләрне китереп чыгарган халыкларның, милләтләрнең хокукларын чикләп яшәгәнбез икән”. Артык шәрехләмә сорамый торган җавап, безнеңчә.

Министр урынбасары хәбәр иткәнчә, көрәшне спорт төре буларак тану турындагы документ тиздән Дәүләт Думасында карала башлаячак. Дөрес, рәсми рәвештә милли төребез танылды дип әйтер өчен аерым процедура узганын көтәргә туры киләчәк.

Паршикова да көрәшне ил күләмендә тану аның халыкара аренага чыгачагына өмет тудыруын билгеләп үтте. “Әйтергә кирәк, Олимпия уеннары программасында булган күп кенә спорт төрләре кайчандыр теге яки бу халыктан алынган, дөнья аренасына да беренче адымнарын студентлар ярышларында ясаган. Кем белә, бәлки 20-30 елдан соң без көрәшне Олимпия уеннары программасында күрербез”, - дип белдерде ул журналистларны шаккаттырып.

Бу очракта шунысын искәртү зарур. Моңарчы татарча көрәшебез Россия тарафыннан танылмаган булса да, халыкара спорт оешмалары безне инде таныды. Татарча көрәшнең FILA составына керү, димәк ки, Халыкара Олимпия комитеты тарафыннан да танылуы күп нәрсә турында сөйли. Татарча көрәш буенча дөнья чемпионаты да үтте, төрле кыйтгаларда да татарча көрәшне белән башладылар. Димәк, безне Мәскәүдән дә иртәрәк дөнья үзе таныган булып чыга түгелме соң?

**Интернет ресурстан**

# Илһам канатында

## Жәй

Менә ямьле җәй дә җитте. Җәй көнне бик тә рәхәт. Барлык табигать яшеллеккә күмелгән. Кояш кыздыра. Һәр агачта чут-чут килеп кошлар сайрыйлар. Тәнгә сихәт биреп, җылы җилләр исәләр, һәр яктан үлән, чәчәк



исе борынны кытыклый. Ниһаять, каникуллар! Җылы кояш нурлары үзләренә тартып торалар, су коенарга чакыралар. Балык та тотоарга еш йөрим.

Җәй көнне футбол да уйныйбыз, велосипедта да йөрибез. Җәйге ял бик рәхәт булса да, мин үземнең сыйныфташларымны һәм безне укыткан укытучыларымны сагынам.

**Радик Идрисов, 4 В сыйныфы укучысы**

## Тукаем

Тукаем син, кыйблам син;
Иманым син, дөньям син;
Анам телен сөйдердең,
“И туган тел”дидердең
Җир йөзенә таныттың
Татар халкын терелттең
Дәрт вә күәтең бирдең
Тукаем, син дидердең!
Аз гомер юлын йөрсәң дә,
Күп белдең син, армадың,
Балаларга шигырь язсаң да
Үзең сабый булып калдың,
Күп еллар узып китсә дә,
Онытмыйбыз үзеңне,
Йөрәкләрдә янып калырсың,
МәңгелекТукай моңы!

**Алсу Ахмадуллина ,5 Гсыйныфы укучысы**

## Тукай васыяте

Хуш мәңге, табигать баласы.
Ятимлек газабын кичереп,
Язгандыр караның карасы:
Артык кашык булып кимсенеп.

Ул сабыр булгындыр, күрәсең:
Язмышы бик ачы булса да,
Мирасның калдырган яктысын,
Тәннәре сырхаулар күрсә дә.

Син иртә киттең бит, диярләр,
Халкыбыз нәүмиз бит диярләр,
Ләкин ничек кенә булмасын,
Килмәгәндер ары каласың.

Синнән соң киләчәк елларны,
Сталинлы репрессив чорларны
Сизгәнсеңдер лә син, Габдулла.
Язмышка хуҗа бит бер Алла.

Эх, белсәң иде син, Тукаем:
Милләтем буталчык бүген дә.
Татарның иң текә яшьләре
Асылын оныта, чынбарын.


Дәүләттә ике тел бар барын...
Әмма ул канунлар кәгазьдә.
Ә кәгазь ул кичерә барын.
Тик үтәлми кала кагыйдә.

Туган тел васыять калдырып,
Туган җир моңнарын тудырдың.
Син кушкан сүзләрне тыңлармын:
Балама телемне ачармын.

Тынычлан син, Тукай, борчылма!
Минем кебекләр дә аз түгел.
Күпчелек буынга тапшыра
Туган телен, асыл сыйфатын.

**Диләрә Валеева, 8 Мсыйныфы укучысы**





**Ә сез, бу турыда белә идегезме?**

Г. Тукай үзен шагыйрь дип исәпләми.Шигырьләрендә моңа ишарә бар:
«Шигырь бабында юк бәндә мәһарәт,
Фәкать бу тугърыда кыйлдым җәсарәт…»

**Ягъни:**
«Шигырь язарга миндә осталык юк,
Тик әле кыюлык итеп кенә яздым.»

**Ахырда болай дип тә куя:**
«Намем Габдулла — Алла бәндәсемен,
Җәмигы колларың шәрмәндәсемен.»

**Ягъни:**
«Исемем Габдулла — Алла бәндәсемен,
Алланың барлык колларыннан иң оялчаны мин.»

Күрәсезме, балалар, бәлки, язуга осталык һәрберебездә дә бардыр, ләкин без аны яшереп кенә ятабыздыр!

**Мөхәррирләр**

# Әдәпле булыгыз!

## Әхлак нигезе—матур гадәт

Баларыбыз тәртипле булып үссеннәр өчен, аларны кечкенә вакыттан ук ашау-эчү әдәпләренә өйрәтергә кирәк: ашарга утырыр алдыннан кулларны юырга, олы кешеләрдән алданнырак өстәл янына утырмаска, уйнамаска; өстәл артыннан торып киткәннән соң, «Рәхмәт» әйтергә онытмаска һәм табын әзерләүчегә өстәлне дә җыештырырга булышу турында истә тотарга кирәк.

## Табын әдәпләре

Әй угыл, ризыкны уң кулың белән аша. Авызыңны тутырып капма. Вак-вак чәйнәп аша, ашың сеңешлерәк булыр. Табынга ашны китергәч, шунда ук ашарга утыр, көттермә. Ашап бетергәч, өстәлдән ашны алмас борын торып китмә. Күп кеше килгән булып, бер генә кеше килеп җитмәгән булса, бер кеше өчен күп кешене көттермә.

## Ашау әдәпләре

Ашарга утырган вакытыгызда, иң элек кулларыгызны юыгыз вә яхшы сөртегез.Үзегездән олы кешеләр булганда, өстәл янына алардан элек утырмагыз.
Аш янында берни белән дә уйнамагыз.Аш янында борыныгызны тартмагыз, чөмереп ашамагыз.Ризыкны зур-зур алмагыз, ашыкмагыз, яхшы чәйнәгез, кул вә киемнәрегезне буямагыз, башкаларның ашавына карап тормагыз, күп ашарга гадәтләнмәгез, аштан күңелегез кайтканчы туктагыз. Бу нәрсәләрнең сәламәтлек өчен файдасы күп икәнлеген үзегез дә белерсез.Чәй янында каймак вә майлы ашлар булса, киемнәрегезгәтамызмагыз, кулларыгызны майламагыз, майлы кулларыгызны киемнәрегезгә сөртмәгез.Аштан соң кул вә авызларыгызны юыгыз, теш арасында бернәрсә калдырмагыз.

**Ризаэддин Фәхреддин:**

Утыр, бәбкәм, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Тәти утыр табында,
Алдыңа күл ясама;
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк аска ташлама.
Карга боткасы түгел бу,
Аягүрә ашама!
================

И әбекәй, әбекәй,
Пешер миңа тәмлекәй.
Пешер бераз әлбә дә,
Янына куш хәлвә дә,
Тагын булса, әбекәй,
Шикәр белән тәмле чәй,
Рәхмәт әйтеп, әбекәй,
Әй итәрмен чәбәкәй!
================

Мә сиңа калак,
Утырма карап.
Аша капкалап,
Иренеңне ялап.

## *Рәсемең нинди—холкың шундый*

***Үзебезнең холкыбызга тагын да ныграк төшенер өчен, әйдәгез, бер гади генә тест үтик. Моның өчен бары чиста кәгазь бите алып, алма рәсеме ясау да җитә. Аны үзегез теләгәнчә ясагыз. Ясадыгызмы? Ә хәзер алма сезгә холкыгызның үзенчәлекләрен “сөйләп” бирер.***

***Түгәрәк, тупка охшаган алма рәсем ясаучының эгоист, үзенең проблемаларын кереп чумган, тирә-юньдәгеләргә игътибарсыз булуы турында сөйли.***

***Яссы, яньчелгәне кешенең аралашучан, юл куючан, ачык булуы*** 

***турында хәбәр итә.***

***Озынча алма хуҗасының төптән фикер йөртә, уйлап эш итә белүен әйтеп бирә.***

***Бер якка авышканны әлеге кешегә шикләнү, оялу хас булуын күрсәтә.***

***Туры, симметрик алма кешенең һәр эштә кискен булуын ачыклый.***

***Уртага бүленгән, төшләре күренеп торганы сезнең бар әйберне дә асылына төшенүегез, һәр күренешнең дә сәбәпләрен таба алуыгыз, гадел булуыгыз турында сөйли.***

***Зур алма ясаганда, рәсем хуҗасының үз-үзенә карата ышанычы булуы, актив тормыш позициясе, лидерлыгы турында хәбәр итә.***

***Кечкенәсе кешенең үз-үзен бәяләве түбән дәрәҗәдә булуын билгели.***

***Яфрагы һәм корты булган алма рәсеме хуҗасының уйлап табучанлыгы, иҗади потенциалы, эмоциональлеге турында сөйли.***

***Штрихланганы хисчәнлек, романтик кәефне аңлата.***

## Истәлекле көн

2013 нче елның 19 нчы мартында Габдулла Тукай мирасын өйрәнүгә багышланган “Без – Тукайлы халык” III республикакүләм Габдулла Тукай укулары үтте. Ул Арча районы Тукай-Кырлай мәктәбендә булды.

Мин, бу укуларда катнашырга теләп, “Табигатьне саклау темасына иҗади эшләр” номинациясенә үзем язган ”Табигать һәм кеше” исемле эссе язып җибәрдем. Минем иҗади эшемне югары бәяләделәр һәм II турга үттем. Шулай итеп, миңа бу укуларда катнашырга насыйп булды. Республиканың төрле төбәкләреннән килгән укучылар арасында чыгыш ясау җиңел булмады, чөнки һәрбер укучы бик әзерлекле һәм төрле жанрларга иҗади эшләре белән чыгыш ясады. Нәтиҗәдә, жюри минем эшемне һәм чыгышымны ошатты. Соңыннан II урын биреп бүләкләделәр. Мин бик сөендем.

Мондый конкурс һәм конференцияләрдә минем беренче генә катнашуым түгел. Бу чаралар укучыларга бик файдалы. Матур яз көнендә Тукай-Кырлай авылын күреп, Тукай музей комплексы белән танышып, башка мәктәп укучылары белән аралашып кайту минем күңелемдә матур хисләр калдырды.

**Зөһрә Рәхиева, 11 В сыйныфы укучысы**

### И туган тел, и матур тел” дигән әдәби -музыкаль кичә

Мәктәптә Габдулла Тукай айлыгы үтте. 24 нче апрельдә бөек шагыйребезгә багышлап “И туган тел, и матур тел” дигән әдәби-музыкаль кичә үткәрдек.Татар драмтүгәрәгенең “Тукай иҗатына сәяхәт” күренеше; ”Әдрән диңгез” җыры; Зәринә Абдуллинаның җырлавы (4б кл.); Лилия Хәбирова (11а кл.), Гөлназ Мотыйгуллина (5м кл.), Радик Идрисов (4в кл.), Диләрә Вәлиева (8м кл.) башкаруында шигырьләр; курайчылар ансамбле (4 кл.) һәм яшь цирк артисты Мусин Булатның (9в ) чыгышлары аеруча уңышлы булды. Кичә халкыбызның гимнына әверелгән “Туган тел” җыры белән тәмамланды.

**Лилия Хәбирова, 11 А сыйныфы укучысы**

## «Мин татарча сөйләшәм!»

“Мин ТАТАРЧА сөйләшәм!”. 26 апрель көнне Казанда әнә шундый акция узды. Бу чараны ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан шәһәре Башкарма комитеты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, “ҮЗЕБЕZ” яңа буын хәрәкәте һәм Бөтендөнья татар яшьләре форумы оештыра.




Хәзерге дөньяда милләт фәкать көндәшлеккә сәләтле шәһәр мәдәниятен булдырганда гына милләт буларак саклана ала дигән фикерләр яши. Ә милләт үзенең теленнән башка яши алмый. Шуңа күрә бүген шәһәрдә татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү көн кадагындагы мәсьәлә. Акция татар теленең шәһәрдә кулланылыш даирәсен киңәйтүгә, татар шәһәр мәдәни мохитен булдыруга хезмәт итә. Ул татар телен популярлаштыру чараларының берсе дә.

26 апрель көнне Бауман урамында әлеге акциядә актив катнашучыларны бүләкләделәр. Мәктәбебезнең татар теле укытучысы Инсафетдинова М.Т. “Интернет татарча сөйләшә” номинациясендә актив катнашып “Рәхмәт хаты” һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнде.

**Камилә Закирова, 7 Г сыйныфы укучысы**

## Очрашу

Күптән түгел безнең сыйныфка очрашуга Сәмигуллин Мулланур абый белән Марданов Риталий абый килгән иде.

Мулланур абый 1982 нче елда Ватанга хезмәт итәргә алынган. 15 ел су асты атом көймәсендә хезмәт иткән.

Риталий абый Тын океан флотында хезмәт иткән вакытта водолаз һөнәренә өйрәнә. Ул безгә күп кенә фоторәсемнәр күрсәтте. Алардан күренгәнчә, ул хайваннарны да ярата икән.

Без сыйныфыбыз белән аларны игътибар белән тыңлап утырдык. Кызыклы хәлләрне, авыр хезмәт юлын безгә сөйләп, аңлатып бирделәр. Үзләренең киңәшләрен җиткерделәр. Мин аларның медальләрен күреп, сокландым.

Мондый очрашулар күбрәк булсыннар иде.

**Илгиз Якубов, 5 А сыйныфы укучысы**

## “Театр яктылыкка, нурга илтә!”

Без 5 М сыйныфының татар төркеме Габдулла Тукайның искә алу көненә, аның әсәрләре буенча спектакль куйдык. Мин әлеге спектакльда авыл малаен уйнадым.

Әйе, сәхнәдә уйнар өчен бик зур осталык кирәк. Репетицияләр саен репетицияләр! Миңа башта авыр иде, рольгә дә тиз генә кереп китеп булмас төсле тоелды. Ә аннары уйный-уйный өйрәндек, оялу хисе дә бераз онытылды.

Спектакльләр белән төрле конкурсларда катнаштык.

Мин быел театр түгәрәгенә йөреп, үземнең рухи үсешем өчен күп нәрсә алдым. Бергә-бергә сыйныфташларым белән спектакльләр куеп йөргәч, ничектер якынаеп, тагын да дуслашып киттек. Икенче елга да шулай катнашып йөрергә тәләгем бик зурдан.

**Илназ Гиматдинов, 5 М сыйныфы укучысы**

## Булачак йолдызыбыз белән таныш булыгыз!

Таныш булыгыз – Зәринә Абдуллина, башкалыбызның Идел буе районы 78 нче мәктәбенең 4 нче Б сыйныфы укучысы.



Укый башлагач, кызның һөнәрләре тагын да артты. Зәринә 14 нче музыка мәктәбендә укый. Вокал, мода һәм бию түгәрәкләренә йөри. Фортепьянода уйнарга өйрәнә. Яраткан көе – “Тәфтиләү”.

“4” ле, “5” ле билгеләренә укуы өстенә, 11 яшьлек Зәринә мәктәпнең сәхнә йолдызы да. Аның җыр-биюгә осталыгы мәктәпкә кабул ителгән көннән билгеле булды. Үзенең матур тавышы белән тирә-юньдәгеләрне сокландырды.

Шушы көннәрдә генә Казанда узган Халыкара җыр һәм бию “Виктория” конкурсыннан 1 нче урын яулап, диплом белән бүләкләнеп кайтты. Кызның җиңүләре әле моның белән генә чикләнми. Ул - шәһәр, республика, Бөтенроссия күләмендә үткәрелгән конкурсларның җиңүчесе дә. Бу җор телле, баскан җирдән ут чыгаручы кызның киләчәге өметле.

Зәринәне “чын җырчы” итеп сәхнәдә күрергә телибез. Уңышлар аңа!

**Зөһрә Рәхиева 11 В сыйныфы укучысы**



## Җиңү көне

Бөтен халык җиңү бәйрәмен каршы ала. Җиңү көне – изге һәм көтеп алынган бәйрәм. Бөек Ватан сугышын һәрбер гаилә белә, чөнки бабайлар, әбиләр, абыйлар бу сугышта катнашкан. Минем бабаем Минҗан улы Галимҗан Бөек Ватан сугышында сержант булып катнашкан. Бөек Җиңү көне — аның иң яраткан бәйрәме. Әлеге сугыш халыкка күп кайгы һәм хәсрәт китергән. Күп кешеләр безнең хәзерге тормыш өчен үз гомерен биргән. Без тарихыбызны белергә һәм онытмаска тиешбез. Бабаларыбыз кебек илебез турында уйларга һәм аны сакларга әзер булырга тиешбез.

**Ләйлә Магеррамова, 5 М сыйныфы укучысы**

## Бөек Җиңү көнен бәйрәм иттек

Бүген Бөек Җиңү көненә 68 ел. Җиңү паркында казан халкы әлеге бәйрәмне зурлап үткәрде. Мәңгелек ут янына



бөтен халык чәчәкләр куйды. Тантанага Татарстан Республикасының президенты Рөстәм Минниханов, Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советының председателе Фәрид Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасының Премьер-министры Илдар Халиков, Казан шәһәренең мэры Илсур Метшин килгәннәр иде.

Безнең мәктәптән 5 нче һәм 6 нчы кадетлар сыйныфы укучылары Җиңү паркында концерт белән чыгыш ясадылар.

**Булат Адгамов, 5 К сыйныфы укучысы**

## Бөек Җиңү көненә – 68 ел!

Бөек Ватан сугышыннан соң ничәмә дистә еллар узды инде. Бер уйласаң, ул онытылырга, тарихи хакыйкать булып кына калырга тиештер кебек. Ләкин юк, исән калган сугыш һәм тыл ветераннырының тән һәм күңел яраларында, имгәтелгән язмышларында, хәтта сугышны күрмәгән миллионнарча кешеләрнең дә авыр кичерешләре дәвам итә.

Мин үземнең дәү эти белән дәү әнием белән горурланам, чөнки алар хәзерге тыныч тормыш өчен көрәшкәннәр. Алар янына кайтсам, сугыштагы хәлләрне еш сөйлиләр, ә күзләре яшь белән тула. “Сугышта барлык кешеләргә дә эш табылып тора иде. Ашарга юк. Шунда төрле үләннәр, ашалмаган кычытканнар калмады инде, черек бәрәңгеләр белән дә туклана идек. Бөтен нәрсә фронт өчен! Булган ризыкны фронтка җибәргәч, ашарга, хәтта, ипи дә юк. Фронтка киткән солдатларга киемнәр тегеп, бәйләп җибәрә идек. Һәрвакыт хатлар яздык. Җавабы килми калса, борчылдык.” – дип, сөйләде минем дәү әнием.

Дәү әни белән дәү этинең медальләре һәм орденнары бик күп. Алар һәр елны Бөек Җиңү бәйрәмен “яңадан туу көне” белән тиңләштерәләр.

Мин үземнең дәү әнием һәм дәү этием белән горурланам. Аларның батырлыклары, илебез азатлыгы өчен көрәшкәннәрә бик рәхмәтлемен. Бөек Җиңү көненә 68 ел узган булса да, без - яшьләр, әлеге бәйрәмне зурлап бәйрәм итәргә, бабаларыбызның батырлыкларын онытмаска тиешбез!

**Алсу Ахмадуллина, 5 Г сыйныфы укучысы**

# Эш беткәч, уйнарга ярый !



## Урманда

«Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк микән?»
Марс килгән урманга
Кура җиләк җыярга.



Җыйсын әле күп итеп,
Какка җитәрлек итеп.

«Җиләк җыям, как коям
Әбиемә бүләк»,— дип.
Әби тәмләп чәй эчәр,
«Улым җыйган җиләк»,
— дип.

**Клара Булатова**

## Болында

Болында, болында
Ал чәчәкләр үсәләр.
Ал чәчәкләрне тирбәтеп,
Җылы җилләр исәләр.

**Хәй Вахит**

## Каен җиләге

Мин качтым сездән,
Эзләп табыгыз,
Тизрәк авызга
Алып кабыгыз.
Минем исемем –
Каен җиләге,
Җиләкләрнең дә
Менә дигәне!
Кызу кояшта
Кызарып пешәм,
Вакытсыз җиргә
Өзелеп төшмәм.
Рәхмәт әйтермен
Җыеп алсагыз,
Корып бетәрмен,
Күрми калсагыз.

**Әминә Бикчәнтәева**

## Бу кайчак була?

Ашлыклар үсте,
Башаклар иште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.
Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура,
— Бу кайчак булла?

**Габдулла Тукай**

## Корыда яуган яңгыр

Иркен сулап куялар да,
Игеннәр: «Рәхмәт! —
диләр. —
Сусап-кибеп беткән идек,
Безгә бик рәхәт!» —диләр .
Ишетәмсең кыярларны,
Кәбестәне, кабакны?
Үрдәкләр, казлар һәммәсе
«Рәхмәт!» диеп кабатлый.
Чәчәкләр дә, агачлар да
Рәхмәт әйтәләр аңа.
Яңгыр ява! Яуган өчен
Яңгырга рәхмәт ява!

**Шәүкәт Галиев**

## Энҗе чәчәк

Килеп керсәң урманга,
Аның исен тоясың,
— Ай-һай, нинди хуш исле,
– дип
Иркен сулап куясың.

Яшел яфраклар эчендә
Энҗе чуклар эленгән,
Искитәрлек матур булып
Ничек үсеп өлгергән.

**Әминә Бикчәнтәева**

## Күбәләк

Кызым, синең эшең бик
күп:
Бакчага барасың да
Күбәләк куып йөрисең
Чәчәкләр арасында.

Чәчәккә кунган күбәләк
Күзен йомып утырмый,
Канат җәеп очып китә,
Еласаң да тоттырмый.

Кума, кызым, күбәләкне,
Бакчабызда йөрсен ул,
Кунсын йомшак
чәчләреңә,
Бантик булып торсын ул.

**Фатих Кәрим**

## Урман докторы

Тукран һәр агачны
Тук-тук-тук сугып карый,
Көчле һәм очлы борыны
Шундый зур эшкә ярый.
Агач кимергән кортларны
Эзләп, чукып бетерә.
Урман докторы булып ул
Бик күп файда китерә.

**Мәрзия Фәйзуллина**

## Табышмаклар

| | | |
|---|---|---|
| Алты – җиде генә булыр<br>Тәнемдәге уемнар.<br>Миннән башка үтми иде<br>Аулак өйләр, уеннар.<br>**(Курай)** | Гармуннарның патшасы<br>мин,<br>Телләрем йөздән артык.<br>Яшьләр кулында йөримен,<br>Тиз генә килмәс картлык.<br>**(Баян)** | Үзе кыллы, үзе телле,<br>Идәндә басып тора.<br>Уйнарга теләгән кеше<br>Иң беренче – утыра.<br>**(Пианино)** |



**Мөхәррирләр:** Л. Хәбирова, З. Рәхиева, Д.Вәлиева, Л. Садыков, Р. Идрисов, З. Ибрагимова, Я. Илгиз, А.Әхмәдуллина.
**Консультант:** Л. И. Исмаилова

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс 268-58-61
E-mail: school_7878@mail.ru S78kzn@edu.tatar.ru
Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин:
https://edu.tatar.ru/priv/school78.htm/page813169.htm
Хатларыгызны түбәндәге адреска юллагыз: lyutsiya_90@mail.ru

Мәктәбем минем